# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Сайлаулар һәм референдумнар турында Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 25 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Сайлау кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 5, № 12 (I өлеш); 2010, № 6; Ватаным Татарстан, 2011, 3 август) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 31 статьяның 2 өлешендә "Интернет" челтәрендә урнаштырыла" сүзләрен "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырыла" сүзләренә алмаштырырга;

2) 32 статьяның 2 өлешендә "юридик затларның бердәй дәүләт реестрына сайлау берләшмәсе турында язма кертелү фактын раслый торган" сүзләрен "сайлау берләшмәсен дәүләт теркәве турында" сүзләренә алмаштырырга;

3) 40 статьяда:
а) 2 өлешнең 1 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;
б) 2 өлешнең $1^1$ пунктында "юридик затларның бердәй дәүләт реестрына сайлау берләшмәсе турында язма кертелү фактын раслый торган" сүзләрен "сайлау берләшмәсен дәүләт теркәве турында" сүзләренә алмаштырырга;

4) 41 статьяда:

а) 1 өлешнең 5 пунктында "юридик затларның бердәй дәүләт реестрына сайлау берләшмәсе турында язма кертелү фактын раслый торган" сүзләрен "сайлау берләшмәсен дәүләт теркәве турында" сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 өлешнең 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"6) иҗтимагый берләшмәләр өчен (сәяси партияләрдән, аларның региональ бүлекләреннән һәм бүтән структур бүлекчәләреннән гайре) – иҗтимагый берләшмә уставының иҗтимагый берләшмәнең даими эшләүче җитәкче органы тарафыннан таныкланган күчермәсен;";

в) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ өлеш өстәргә:

"$1^1$. Сайлау берләшмәсе тарафыннан кандидатлар берничә бермандатлы һәм (яисә) күпмандатлы сайлау округлары буенча күрсәтелгән очракта, кандидатларны теркәүче сайлау комиссиясенә әлеге статьяның 1 өлешендәге 5 һәм 6 пунктларында каралган документларны сайлау берләшмәсенең вәкаләтле вәкиле йә әлеге документларны беренче булып тапшырган, шушы сайлау берләшмәсе тарафыннан күрсәтелгән кандидат тапшырырга мөмкин. Мондый очракта шушы сайлау берләшмәсе тарафыннан күрсәтелгән бүтән кандидатлар әлеге статьяның 1 өлешендәге 5 һәм 6 пунктларында каралган документларны шул ук сайлау комиссиясенә тапшырмаска да мөмкин.";

5) 42 статьяда:

а) 1 өлешнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1) иҗтимагый берләшмәләр өчен (сәяси партияләрдән, аларның региональ бүлекләреннән һәм бүтән структур бүлекчәләреннән гайре) – иҗтимагый берләшмә уставының иҗтимагый берләшмәнең даими эшләүче җитәкче органы тарафыннан таныкланган күчермәсен;";

б) 1 өлешнең 3 пунктында "юридик затларның бердәй дәүләт реестрына сайлау берләшмәсе турында язма кертелү фактын раслый торган" сүзләрен "сайлау берләшмәсен дәүләт теркәве турында" сүзләренә алмаштырырга;

6) 43 статьяда:

а) 3 өлештә "гомуми файдаланудагы "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге" сүзләрен "Интернет" челтәрендәге" сүзләренә алмаштырырга;

б) 5 өлештә "гомуми файдаланудагы "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге" сүзләрен "Интернет" челтәрендәге" сүзләренә алмаштырырга;

7) 44 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"44 статья. **Кандидатны, кандидатлар исемлеген күрсәтүне хуплап сайлаучылар имзаларын җыю һәм имза кәгазьләрен рәсмиләштерү тәртибе**

1. Дәүләт Советы депутатларын сайлауларда имзалар имза кәгазьләре әзерләгән өчен түләү көненнән җыела башларга мөмкин. Җирле үзидарә органнарына сайлауларда имзалар кандидатны күрсәтү турында комиссиягә хәбәр

ителгән, кандидатлар исемлеге таныкланган көннән соң килүче көннән җыела башларга мөмкин. Имзалар бары тик кандидат, кандидатлар исемлеге күрсәтелгән сайлау округында актив сайлау хокукына ия булган сайлаучылар арасында гына җыелырга мөмкин.

2. Сайлаучылар имзаларын җыю хокукына имзалар җыю вакытына 18 яше тулган һәм суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез дип танылмаган Россия Федерациясе гражданы ия. Кандидат, сайлау берләшмәсе сайлаучылар имзаларын җыючы зат белән имзалар җыю турында шартнамә төзергә мөмкин. Бу эшкә түләү кандидатның, сайлау берләшмәсенең сайлау фонды акчаларыннан гына гамәлгә ашырыла.

3. Сайлаучылар имзаларын җыюга бәйле барлык чыгымнар кандидатның, сайлау берләшмәсенең сайлау фонды акчалары исәбеннән генә гамәлгә ашырыла.

4. Сайлаучылар имзаларын җыю яшәү урыны буенча һәм сайлау алды агитациясен алып бару һәм имзалар җыю федераль закон белән тыелмаган башка урыннарда гамәлгә ашырылырга мөмкин.

5. Дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, милек рәвешләренә бәйсез рәвештә оешмаларның идарә органнарының, учреждениеләрнең, сайлау комиссияләренең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзаларының сайлаучылар имзаларын җыюда катнашуы рөхсәт ителми. Имзалар җыю процессында сайлаучыларны үз имзаларын куярга мәҗбүр итү һәм аларны теләсә нинди рәвештә бүләкләү тыела. Эш урыннарында, уку урынында, хезмәт хакы, пенсияләр, пособиеләр, стипендияләр, башка социаль түләүләр бирү барышында һәм урыннарында, шулай ук хәйрия ярдәме күрсәткәндә сайлаучылар имзаларын җыю тыела.

6. Сайлаучылар имзаларын җыю аларны имза кәгазьләренә кертү юлы белән гамәлгә ашырыла. Имза кәгазьләре тиешле сайлау фонды акчалары исәбеннән әзерләнә. Дәүләт Советы депутатларына кандидатлар исемлекләрен күрсәтүне, кандидатларны күрсәтүне (үз-үзен күрсәтүне) хуплап сайлаучылар имзаларын җыю өчен имза кәгазьләре – "Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль законның 4 нче һәм 5 нче кушымталары нигезендәге, муниципаль берәмлек башлыгы вазыйфасына кандидатны күрсәтүне (үз-үзен күрсәтүне) хуплап – "Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль законның 6 нчы кушымтасы нигезендәге, муниципаль берәмлек вәкиллекле органы депутатларына кандидатлар исемлекләрен күрсәтүне, кандидатларны күрсәтүне (үз-үзен күрсәтүне) хуплап "Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль законның 7 нче һәм 8 нче кушымталары нигезендәге рәвешләр буенча әзерләнә һәм рәсмиләштерелә. Муниципаль берәмлек сайланулы органы әгъзаларын күрсәтүне хуплап сайлаучылар имзаларын җыю өчен имза кәгазьләре әлеге Кодексның 1 нче кушымтасы нигезендәге рәвеш буенча әзерләнә һәм рәсмиләштерелә.

7. Белешмәләре имза кәгазендә күрсәтелә торган Дәүләт Советы депутатларына кандидатның, муниципаль берәмлек башлыгы вазыйфасына кандидатның, муниципаль берәмлек вәкиллекле органы депутатларына

кандидатның, муниципаль берәмлек сайланулы органы әгъзаларына кандидатның алынмаган һәм юкка чыгарылмаган хөкем ителүе булган очракта, кандидатның хөкем ителүе турындагы белешмәләр имза кәгазендә өстәмә рәвештә күрсәтелә. Әгәр үзләре турындагы белешмәләр имза кәгазендә була торган Дәүләт Советы депутатларына кандидат, муниципаль берәмлек башлыгы вазыйфасына кандидат, муниципаль берәмлек вәкиллекле органы депутатларына кандидат, муниципаль берәмлек сайланулы органы әгъзаларына кандидат Дәүләт Советына, җирле үзидарә органына чыгуга ризалыгы турындагы гаризасында әлеге Кодексның 39 статьясындагы 2 өлеше, 40 статьясындагы 3 өлешенең 1 пункты, 41 статьясындагы 2 өлеше, 42 статьясындагы 2 өлешенең 1 пункты нигезендә үзенең сәяси партиядән йә бүтән иҗтимагый берләшмәдән булуын һәм әлеге сәяси партиядәге йә әлеге иҗтимагый берләшмәдәге статусын күрсәтсә, бу хактагы белешмәләр имза кәгазендә күрсәтелә.

8. Дәүләт Советына сайлауларда имза кәгазендә имза кәгазьләрен әзерләү өчен түләү башкарылган махсус сайлау счетының номеры күрсәтелә.

9. Сайлаучы имза кәгазендә үз имзасын куя һәм аны кую датасын күрсәтә, шулай ук үзенең фамилиясен, исемен, атасының исемен, туган елын (тавыш бирү көненә 18 яшьтә булса, өстәмә рәвештә туган көнен һәм аен), яшәү урынының адресын, паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы документының сериясен, номерын күрсәтә. Имза кәгазендә үз имзасын куя торган һәм аны кую датасын күрсәтә торган сайлаучы турындагы күрсәткечләр сайлаучы үтенече буенча имза кәгазенә кандидатны, кандидатлар исемлеген хуплап имзалар җыючы зат тарафыннан да кертелергә мөмкин. Әлеге күрсәткечләр бары тик кулдан гына язылa, бу чакта карандаш куллану рөхсәт ителми. Имзасын һәм аны кую датасын сайлаучы үз кулы белән яза. Сайлаучы төрле кандидатларны, кандидатлар исемлекләрен күрсәтүне хуплап имза куярга, әмма бер үк кандидатны, кандидатлар исемлеген хуплап бер генә мәртәбә имза куярга хокуклы.

10. Һәр имза кәгазе сайлаучылар имзаларын җыючы затның имзасы белән таныкланырга тиеш. Сайлаучылар имзаларын җыючы зат, имза кәгазен таныклаганда, үз кулы белән үзенең фамилиясен, исемен һәм атасының исемен, туу датасын, яшәү урынының адресын, паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы документының сериясен, номерын һәм бирелү датасын, аны биргән органның исемен яисә кодын, шулай ук үз имзасын куя һәм аны кую датасын күрсәтә.

11. Кандидатлар исемлеген күрсәтүне хуплап сайлаучылар имзалары булган һәр имза кәгазе сайлау берләшмәсенең вәкаләтле вәкиле тарафыннан таныкланырга тиеш. Кандидатны күрсәтүне (үз-үзен күрсәтүне) хуплап сайлаучылар имзалары булган һәр имза кәгазе кандидат тарафыннан таныкланырга тиеш. Имза кәгазен таныклаганда, сайлау берләшмәсенең вәкаләтле вәкиле, кандидат үзенең фамилиясе, исеме һәм атасының исеме каршына үз кулы белән имзасын куя һәм аны кую датасын күрсәтә.

12. Кандидатны, кандидатлар исемлеген күрсәтүне хуплап имзалар җыйганда, имза кәгазенең алгы ягын да, арткы ягын да тутыру рөхсәт ителә. Бу чакта имза кәгазенең арткы ягы имзаларның бердәм номеры белән алгы якның дәвамы булып

тора, ә таныклау язулары имза кәгазенең арткы ягында сайлаучының соңгы имзасыннан соң ук куела.

13. Имзалар җыю тәмамланганнан соң, кандидат, сайлау берләшмәсенең вәкаләтле вәкилләре сайлаучыларның җыелган имзаларының гомуми санын саныйлар һәм сайлауларны оештыручы сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән рәвеш буенча имзалар җыю йомгаклары турында ике нөсхәдә беркетмә төзиләр. Беркетмәнең һәр нөсхәсенә тәңгәл рәвештә кандидат, сайлау берләшмәсенең вәкаләтле вәкиле имза куя.

14. Имза кәгазьләре, брошюраланган һәм номерлар куелган килеш, сайлау комиссиясенә тапшырыла. Сайлау комиссиясенә, имза кәгазьләре белән бергә, имзалар җыю йомгаклары турындагы беркетмә ике нөсхәдә кәгазь чыганакта килеш һәм машинадан укылырлык рәвештә тапшырыла.";

8) 45 статьяның 2 өлешендәге 3 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

9) 46 статьяда:

а) 7 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"7. Кандидатларны, кандидатлар исемлеген күрсәтү тәртибенең, сайлаучылар имзаларын җыю һәм имза кәгазьләрен рәсмиләштерү тәртибенең үтәлешен, имза кәгазьләрендәге сайлаучылар турындагы белешмәләрнең һәм аларның имзаларының дөреслеген тикшерү өчен сайлау комиссиясе үз карары белән сайлау комиссиясе әгъзаларыннан, аның аппараты хезмәткәрләреннән һәм җәлеп ителгән белгечләрдән эш төркемнәре төзергә мөмкин. Тикшерүгә түбәнгерәк комиссия әгъзалары, эчке эшләр органнарының, юстиция учреждениеләренең, хәрби комиссариатларның, Россия Федерациясе гражданнарын Россия Федерациясе чикләрендә булу урыны буенча һәм яшәү урыны буенча теркәп исәпкә алу органнарының, шулай ук башка дәүләт органнарының белгечләре арасыннан экспертлар җәлеп ителергә мөмкин. Экспертларның бәяләмәләре имза кәгазьләрендәге сайлаучылар турындагы белешмәләрне һәм аларның имзаларын дөрес түгел һәм (яисә) гамәлгә яраксыз дип тану өчен нигез булырга мөмкин. Экспертларның бәяләмәләре имза кәгазьләрен тикшерү ведомостьларында яисә бүтән документта язма рәвештә бәян ителә.";

б) түбәндәге эчтәлекле $7^1$ өлеш өстәргә:

"$7^1$. Дәүләт Советына депутатлар, территориаль бүленеше булмаган шәһәр округының, муниципаль районның башлыгын һәм вәкиллекле органы депутатларын сайлауларда имза кәгазьләрендәге сайлаучылар турындагы белешмәләрнең дөреслеген билгеләү өчен "Сайлаулар" ДАС кулланыла, моңа сайлаучылар регистры да керә. Территориаль бүленеше булган шәһәр округы, җирлек башлыгын һәм вәкиллекле органы депутатларын сайлауларда имза кәгазьләрендә сайлаучылар турындагы белешмәләрнең дөреслеген билгеләү өчен Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары буенча "Сайлаулар" ДАС кулланылырга мөмкин, моңа сайлаучылар регистры да керә.";

в) 13 – 17 өлешләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"13. Сайлаучыларның имзаларын һәм имза кәгазьләрендә сайлаучылар турындагы аларга туры килүче белешмәләрне тикшерү нәтиҗәләре буенча сайлаучы имзасы дөрес йә дөрес түгел һәм (яисә) гамәлгә яраксыз дип танылырга мөмкин.

14. Бер затның икенче зат исеменнән куелган имзасы әлеге статьяның 7 өлеше нигезендә сайлаучылар имзаларын тикшерү эшенә җәлеп ителгән эксперт бәяләмәсе нигезендә дөрес түгел дип танала.

15. Гамәлгә яраксыз дип түбәндәгеләр танала:

1) имза кәгазьләрен әзерләгән өчен түләү көненә кадәр, ә җирле үзидарә органнарына сайлауларда – кандидатны күрсәтү турында сайлау комиссиясе хәбәр иткән, кандидатлар исемлеген таныклаган көннән соң килүче көнгә кадәр җыелган сайлаучылар имзалары;

2) актив сайлау хокукына ия булмаган затлар имзалары;

3) имза кәгазендә дөреслеккә туры килми торган белешмәләр күрсәткән сайлаучылар имзалары. Бу очракта имза Россия Федерациясе гражданнарын Россия Федерациясе чикләрендә булу урыны буенча һәм яшәү урыны буенча теркәү белән шөгыльләнүче органның рәсми белешмәсе йә әлеге статьяның 7 өлеше нигезендә сайлаучылар имзаларын тикшерү эшенә җәлеп ителгән эксперт бәяләмәсе булганда гына гамәлгә яраксыз дип танылырга мөмкин;

4) "Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль закон нигезендә таләп ителә торган теге яисә бу белешмә күрсәтелмәгән һәм (яисә) сайлаучының үз имзасын имза кәгазенә үз кулы белән кертү датасы күрсәтелмәгән сайлаучылар имзалары;

5) үзләре турындагы белешмәләр имза кәгазенә кулдан язылмыйча яисә карандаш белән кертелгән сайлаучылар имзалары;

6) имза кәгазенә кертү даталарында төзәтүләре булган сайлаучылар имзалары, әгәр бу төзәтүләр сайлаучылар белән махсус килештерелмәгән булса, шулай ук кертү даталары сайлаучыларның үз кулы белән язылмаган сайлаучылар имзалары – сайлаучылар имзаларын тикшерү эшенә әлеге статьяның 7 өлеше нигезендә җәлеп ителгән эксперт бәяләмәсе нигезендә;

7) сайлаучылар турындагы аларга туры килә торган белешмәләрдәге төзәтүләре булган сайлаучылар имзалары, әгәр бу төзәтүләр сайлаучылар яисә сайлаучылар имзаларын җыючы затлар тарафыннан махсус килештерелмәгән булса;

8) имза кәгазе сайлаучылар имзаларын җыйган затның һәм (яисә) кандидатлар исемлеген күрсәткән сайлау берләшмәсенең вәкаләтле вәкиленең, кандидатның үз кулы белән куелган имзалары белән таныкланмаган булса, йә имзаларның берәрсе генә дөрес булмаса, йә имза кәгазе имзалар җыю мизгеленә 18 яшькә җитмәгән, сайлаучылар имзаларын җыйган зат тарафыннан таныкланган булса һәм (яисә) әлеге зат суд тарафыннан хокукка сәләтсез дип танылган булса, йә имза кәгазен таныклау даталарының берәрсе генә кулдан күрсәтелмәгән яисә кертелмәгән булса, йә сайлаучылар имзаларын җыйган зат турындагы белешмәләрдә һәм (яисә) шушы зат һәм (яисә) кандидатлар исемлеген күрсәткән сайлау берләшмәсенең вәкаләтле вәкиле, кандидат тарафыннан имзалар кертү датасында сайлаучылар имзаларын җыйган зат белән, кандидатлар исемлеген күрсәткән сайлау берләшмәсенең вәкаләтле вәкиле, кандидат белән тәңгәл рәвештә махсус килештерелмәгән төзәтүләр булса, йә сайлаучылар имзаларын җыйган зат турындагы һәм (яисә) кандидатлар исемлеген күрсәткән сайлау берләшмәсенең вәкаләтле вәкиле турындагы, кандидат турындагы белешмәләр имза кәгазендә тулы күләмдә

күрсәтелмәгән булса яисә дөреслеккә туры килмәсә, йә сайлаучылар имзаларын җыйган зат турындагы белешмәләр аның үз кулы белән кертелмәгән булса;

9) "Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль законның 4 – 8 нче кушымталары, шулай ук әлеге Кодексның 1 нче кушымтасы таләпләренә туры килми торган рәвештәге, һәм (яисә) әлеге Кодексның 44 статьясындагы 7 һәм 8 өлешләрендә каралган белешмәләр кертелмәгән, һәм (яисә) әлеге Кодексның 44 статьясындагы 6 өлешендә каралган таләпләрне үтәмәгән килеш әзерләнгән имза кәгазендәге барлык сайлаучылар имзалары;

10) әлеге Кодексның 44 статьясындагы 1 һәм 5 өлешләрендә каралган таләпләрне бозган килеш җыелган сайлаучылар имзалары;

11) сайлаучылар имзалары, әгәр имза кәгазенә сайлаучылар турындагы белешмәләр имза куйган сайлаучыларның үзләре тарафыннан һәм сайлаучылар имзаларын җыючы зат тарафыннан кертелмәгән булса, – сайлаучылар имзаларын тикшерү эшенә әлеге статьяның 7 өлеше нигезендә җәлеп ителгән эксперт бәяләмәсе нигезендә;

12) сайлаучылар имзаларын җыючы зат һәм (яисә) кандидатлар исемлеген күрсәткән сайлау берләшмәсенең вәкаләтле вәкиле, кандидат тарафыннан имза кәгазе таныкланганнан соңрак имза кәгазенә кертелгән сайлаучылар имзалары;

13) имза кәгазендәге барлык сайлаучылар имзалары, әгәр сайлаучылар имзаларын җыючы затның таныклау язмасы кандидатлар исемлеген күрсәткән сайлау берләшмәсенең вәкаләтле вәкиле, кандидат тарафыннан таныклау язмасы кертелгәннән соңрак кертелгән булса.

16. Сайлаучылар имзаларын тикшергәндә, бер үк кандидатны, кандидатлар исемлеген күрсәтүне хуплап бер үк сайлаучының берничә имзасы табылса, бер генә имза дөрес дип санала, ә калган имзалар гамәлгә яраксыз дип санала.

17. Имза кәгазендә әлеге Кодекс таләпләренә туры килми торган тутырылган юл (тутырылган юллар) табылганда, шул юлдагы (шул юллардагы) имза гына исәпкә алынмый, моңа әлеге статьяның 15 өлешендәге 8, 9 һәм 13 пунктларында каралган очраклар керми.";

г) 19 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"19. Әгәр әлеге статьяның 15 өлешендәге 8, 9 һәм 13 пунктлары нигезендә сайлаучы имзасының дөрес түгеллеге яисә гамәлгә яраксызлыгы билгеләнмәгән булса, имза кәгазен төзегәндә сайлаучы яисә имза кәгазен таныклаучы зат белән махсус килештерелгән төзәтүләр һәм ялгышлар сайлаучы имзасын гамәлгә яраксыз дип тану өчен нигез була алмый.";

10) 55 статьяның 7 өлешендә "гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә ("Интернет"ны да кертеп)" сүзләрен "аерым затлар даирәсе керү белән генә чикләнмәгән мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә ("Интернет" челтәрен дә кертеп)" сүзләренә алмаштырырга;

11) 56 статьяның 3 өлешендә "гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә ("Интернет"ны да кертеп)" сүзләрен "аерым

затлар даирәсе керү белән генә чикләнмәгән мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә ("Интернет" челтәрен дә кертеп)" сүзләренә алмаштырырга;

12) 58 статьяның 11 өлешендә "гомуми файдаланудагы" сүзләрен төшереп калдырырга;

13) 63 статьяның $4^1$ өлешендә "гомуми файдаланудагы" сүзләрен төшереп калдырырга;

14) 77 статьяда:

а) 5 өлештә "тавыш бирү вакыты тәмамланырга дүрт сәгатьтән дә соңга калмыйча" сүзләрен "участок комиссиясе төзелгәннән соң теләсә кайсы вакытта, әмма тавыш бирү вакыты тәмамланырга алты сәгатьтән дә соңга калмыйча" сүзләренә алмаштырырга, түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: "Күрсәтелгән сроктан соң кергән гариза (телдән мөрәҗәгать) канәгатьләндерелмәскә тиеш, бу хакта сайлаучыга йә мөрәҗәгатьне тапшыруда ярдәм иткән затка гаризаны (телдән мөрәҗәгатьне) кабул иткән мизгелгә турыдан-туры телдән хәбәр ителә.";

б) 6 өлешкә "игълан итәргә" сүзләреннән соң ", шулай ук участок комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзаларына һәм күзәтүчеләргә аны уздырганда катнашу тәкъдим ителергә" сүзләрен өстәргә;

в) 8 өлештә "участок комиссиясе" сүзләрен "турыдан-туры югарырак сайлау комиссиясе карары белән, ә җирле үзидарә органнарына сайлаулар уздырганда бердәм сайлау округы территориясе сайлау участогы территориясе белән туры килсә, – участок комиссиясе" сүзләренә алмаштырырга, түбәндәге эчтәлекле җөмләләр өстәргә: "Төрле дәрәҗәдәге сайлауларда һәм (яисә) референдумнарда тавыш бирү көннәре туры килгән очракта, карар югарырак дәрәҗәдәге сайлауларны (референдумны) әзерләүдә һәм уздыруда катнашучы сайлау комиссиясе тарафыннан кабул ителә. Бу чакта тавыш бирү көнендә бер сайлау участогында тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирү өчен кулланыла торган күчерелмә әрҗәләрнең максималь саны сайлау участогы территориясендә теркәлгән сайлаучылар санына бәйле рәвештә түбәндәгечә төзелә:

1) 501 сайлаучыга кадәр – тавыш бирү өчен 1 күчерелмә әрҗә;

2) 501 сайлаучыдан алып 1001 сайлаучыга кадәр – тавыш бирү өчен 2 күчерелмә әрҗә;

3) 1000 сайлаучыдан да артыграк – тавыш бирү өчен 3 күчерелмә әрҗә.";

г) түбәндәге эчтәлекле $8^1$ өлеш өстәргә:

"$8^1$. Әлеге статьяның 8 өлешендә күрсәтелгән тиешле сайлау комиссиясе карары белән тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирү өчен кулланыла торган күчерелмә әрҗәләрнең әлеге статьяның 8 өлешендәге 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән саны, түбәндәге шартларның берсе генә булса да, арттырылырга да мөмкин, әмма 1 күчерелмә әрҗәдән күбрәккә арттырылмаска тиеш:

1) сайлау участогына берничә торак пункт территориясе керсә, һәм тавыш бирү урыны урнашкан торак пункт башка торак пунктларга тавыш бирү вакыты эчендә җәяү барып җитәрлек булмаса;

2) сайлау участогы төзелмәгән сайлаучылар вакытлыча булу урыны сайлау участогы территориясендә урнашкан булса;

3) сайлау участогы территориясендә "Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль законның 16 статьясындагы 10 пункты нигезендә 80 яшьтән өлкәнрәк һәм (яисә) инвалид 50дән артык сайлаучы теркәлгән булса, алар турындагы белешмәләр "Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль законның 20 статьясындагы $16^1$ пункты нигезендә тапшырылган булса;

4) берничә сайлауларда тавыш бирү көннәре туры килгәндә сайлаучы бер үк вакытта икедән артык сайлау бюллетене буенча тавыш бирә алса.";

д) 9 өлешкә түбәндәге эчтәлекле яңа икенче җөмлә өстәргә: "Алына торган бюллетеньнәрнең гомуми саны китү мизгеленә алынган гаризалар (телдән мөрәҗәгатьләр) санының 5 процентыннан артыграк булмаска тиеш (әмма кимендә ике бюллетень).";

15) 79 статьяда:

а) 22 өлештә "9 кушымтасы нигезендә" сүзләрен "2 нче кушымтасы нигезендә" сүзләренә алмаштырырга;

б) 32 өлештә "гомуми файдаланудагы" сүзләрен төшереп калдырырга;

16) 80 статьяның 7 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"7. Түбәнгерәк сайлау комиссияләре беркетмәләрендәге күрсәткечләр буенча югарырак сайлау комиссиясе тавыш бирү йомгаклары турында (сайлаулар нәтиҗәләре турында) беркетмә төзи. Тавыш бирү йомгаклары турындагы (сайлаулар нәтиҗәләре турындагы) беркетмәгә тиешле сайлау комиссиясе тарафыннан алынган бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары саны, түбәнгерәк сайлау комиссияләренә бирелгән бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары саны, тиешле сайлау комиссиясе тарафыннан юкка чыгарылып, файдаланылмый калган бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары саны һәм тиешле сайлау комиссиясендә югалган бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары саны турындагы күрсәткечләр кертелә. Тавыш бирү йомгаклары турында (сайлаулар нәтиҗәләре турында) сайлау комиссиясе тарафыннан (участок комиссиясенә карата турыдан-туры югарырак торган сайлау комиссиясеннән гайре) төзелә торган җыелма таблицага түбәнгерәк сайлау комиссиясе беркетмәсенең тиешле сайлау комиссиясе тарафыннан алынган бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары саны, түбәнгерәк сайлау комиссияләренә бирелгән бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары саны, тиешле сайлау комиссиясе тарафыннан юкка чыгарылып, файдаланылмый калган бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары саны һәм тиешле сайлау комиссиясендә югалган бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары саны турындагы күрсәткечләр кертелә. Беркетмәгә имза кую өчен сайлау комиссиясе мәҗбүри тәртиптә йомгаклау утырышы уздыра, анда тавыш бирүне уздыруга, тавышларны санауга һәм түбәнгерәк сайлау комиссияләренең беркетмәләрен төзүгә бәйле рәвештә сайлау комиссиясенә кергән шикаятьләр (гаризалар) карала. Шуннан соң сайлау

комиссиясе тавыш бирү йомгаклары турындагы (сайлаулар нәтиҗәләре турындагы) беркетмәгә имза куя һәм әлеге Кодексның 21 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән затларга беркетмәнең күчермәләрен бирә. Тавыш бирү йомгаклары турындагы (сайлаулар нәтиҗәләре турындагы) беркетмә ике нөсхәдә төзелә, һәм аңа сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия шунда булган барлык әгъзалары имза куя, анда имза кую датасы һәм вакыты (сәгате һәм минутлары) куела. Беркетмәгә әлеге тәртипне бозып имза кую беркетмәне гамәлгә яраксыз дип тану өчен нигез булып тора.";

17) 91 статьяның 13 пунктында "рәвешен" сүзен "текстын" сүзенә алмаштырырга;

18) 101 статьяның 4 өлешендә "гомуми кулланылыштагы мәгълүмат-телекоммуникация "Интернет" челтәрендә" сүзләрен "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә" сүзләренә алмаштырырга;

19) 103 статьяда:

а) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: "Элегрәк депутат мандаты алган һәм вәкаләтләре шулай ук вакытыннан алда туктатылган теркәлгән кандидатның вакантлы депутат мандаты биләнмәгән булса да, аңа депутат мандаты тапшырыла алмый.";

б) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ һәм $1^2$ өлешләр өстәргә:

"$1^1$. Кандидатларның республика исемлеге арасында депутат мандатларын бүлешү нәтиҗәсендә сайланган Дәүләт Советы депутаты вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, әлеге депутат кандидатларның республика исемлеге составында сайланган сәяси партиянең даими эшләүче коллегиаль җитәкче органы йә аның әлеге депутат кандидатларның республика исемлеге составында сайланган региональ бүлекчәсенең даими эшләүче коллегиаль җитәкче органы (әгәр бу сәяси партия уставы белән каралган булса) вакантлы депутат мандатын биләү өчен кандидатларның шул ук республика исемлегеннән теркәлгән кандидат кандидатурасын тәкъдим итәргә хокуклы.

$1^2$. Теркәлгән кандидат кандидатурасы әлеге статьяның $1^1$ өлеше нигезендә вакантлы депутат мандатын биләү өчен депутат вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында Дәүләт Советы тарафыннан карар кабул ителгән көннән 14 көн эчендә тәкъдим ителергә мөмкин. Кандидатураны тәкъдим итү сәяси партия уставында каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе вакантлы депутат мандатын сәяси партиянең, аның региональ бүлекчәсенең даими эшләүче коллегиаль җитәкче органы тарафыннан тәкъдим ителгән теркәлгән кандидатка тапшыра.";

в) түбәндәге эчтәлекле 4 һәм 5 өлешләр өстәргә:

"4. Кандидатларның республика исемлегенә кертелгән теркәлгән кандидат депутат мандатларын биләүдә (алуда) ике мәртәбәдән артыграк катнашырга хокуклы түгел.

5. Депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән кандидатларның республика исемлегенә яисә әлеге Кодексның $97^1$ статьясы нигезендә депутат мандатлары

тапшырылган кандидатларның республика исемлегенә кертелгән теркәлгән кандидат әлеге республика исемлегеннән түбәндәге очракта төшереп калдырыла:

1) теркәлгән кандидат кандидатларның республика исемлегеннән үзен төшереп калдыру турында язма гариза биргән;

2) теркәлгән кандидат пассив сайлау хокукын югалткан;

3) теркәлгән кандидат, кандидатларның республика исемлегенә кертелгән сәяси партиядә торган килеш, бүтән сәяси партия әгъзалыгына кергән;

4) теркәлгән кандидат депутат мандатын биләүдә (алуда) катнашу хокукын гамәлгә ашырган, шул исәптән әлеге статьяның 4 өлеше нигезендә ике мәртәбә;

5) теркәлгән кандидат хәбәрсез юкка чыккан йә закон көченә кергән суд карары нигезендә вафат булган дип танылган;

6) теркәлгән кандидат вафат булган.";

20) 122 статьяда:

а) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: "Элегрәк депутат мандаты алган һәм вәкаләтләре шулай ук вакытыннан алда туктатылган теркәлгән кандидатның вакантлы депутат мандаты биләнмәгән булса да, аңа депутат мандаты тапшырыла алмый.";

б) түбәндәге эчтәлекле $3^1$ һәм $3^2$ өлешләр өстәргә:

"$3^1$. Кандидатлар исемлекләре арасында депутат мандатларын бүлешү нәтиҗәсендә сайланган депутат вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, әлеге депутат кандидатлар исемлеге составында сайланган сәяси партиянең даими эшләүче коллегиаль җитәкче органы йә аның әлеге депутат кандидатлар исемлеге составында сайланган региональ бүлекчәсенең даими эшләүче коллегиаль җитәкче органы (әгәр бу сәяси партия уставы белән каралган булса) вакантлы депутат мандатын биләү өчен кандидатларның шул ук исемлегеннән теркәлгән кандидат кандидатурасын тәкъдим итәргә хокуклы.

$3^2$. Теркәлгән кандидат кандидатурасы әлеге статьяның $3^1$ өлеше нигезендә вакантлы депутат мандатын биләү өчен депутат вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан карар кабул ителгән көннән 14 көн эчендә тәкъдим ителергә мөмкин. Кандидатураны тәкъдим итү сәяси партия уставында каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла. Муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе вакантлы депутат мандатын сәяси партиянең, аның региональ бүлекчәсенең яисә бүтән структур бүлекчәсенең даими эшләүче коллегиаль җитәкче органы тарафыннан тәкъдим ителгән теркәлгән кандидатка тапшыра.";

в) түбәндәге эчтәлекле 5 һәм 6 өлешләр өстәргә:

"5. Кандидатлар исемлегенә кертелгән теркәлгән кандидат депутат мандатларын биләүдә (алуда) ике мәртәбәдән артыграк катнашырга хокуклы түгел.

6. Депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән кандидатлар исемлегенә кертелгән теркәлгән кандидат әлеге исемлектән түбәндәге очракта төшереп калдырыла:

1) теркәлгән кандидат кандидатлар исемлегеннән үзен төшереп калдыру турында язма гариза биргән;

2) теркәлгән кандидат пассив сайлау хокукын югалткан;

3) теркәлгән кандидат, кандидатлар исемлегенә кертелгән сәяси партиядә торган килеш, бүтән сәяси партия әгъзалыгына кергән;

4) теркәлгән кандидат депутат мандатын биләүдә (алуда) катнашу хокукын гамәлгә ашырган, шул исәптән әлеге статьяның 5 өлеше нигезендә ике мәртәбә;

5) теркәлгән кандидат хәбәрсез юкка чыккан йә закон көченә кергән суд карары нигезендә вафат булган дип танылган;

6) теркәлгән кандидат вафат булган.";

21) 1 нче һәм 2 нче кушымталарны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1 нче кушымта

## ИМЗА КӘГАЗЕ

____________________ муниципаль берәмлеге _________________ әгъзаларын сайлаулар
(муниципаль берәмлек исеме) <1> (сайланулы орган исеме)

__________ елның "____" ____________
(тавыш бирү датасы)

Без, түбәндә имза куючылар, ____________________________________________ буенча
(сайлау округының исеме яисә номеры)

_________________________ туган, __________________________________________ яшәүче,
(туу датасы) (яшәү урыны урнашкан Россия Федерациясе субъекты, район, шәһәр, башка торак пункт исеме)

___________________________________ эшләүче ____________________________ гражданы
(эш урыны, биләгән вазыйфасы яисә шөгыленең төре) (гражданлыгы)

_____________________________________ __________________________ муниципаль берәмлеге
(кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме) (муниципаль берәмлек исеме)

____________________________ әгъзалыгына кандидатның _____________________ хуплыйбыз.
(сайланулы орган исеме) (үз-үзен күрсәтүен яисә, сайлау берләшмәсе исемен күрсәтеп, сайлау берләшмәсеннән күрсәтелүен)

| № т/с | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Туган елы (18 яшендә – өстәмә рәвештә туган көне һәм ае) | Яшәү урынының адресы | Паспортының яисә аны алмаштыручы документының сериясе һәм номеры | Имза кую датасы | Имзасы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | | | |
| 2 | | | | | | |
| 3 | | | | | | |
| ... | | | | | | |

Имза кәгазен таныклыйм: ______________________________________________________
(имзаларны җыйган затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, яшәү урынының адресы, паспортының яисә аны алмаштыручы документының номеры һәм сериясе, шуны биргән органның исемен һәм кодын күрсәтеп, аны бирү датасы, әлеге затның имзасы һәм аны кую датасы)

Кандидат: ______________________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме, имзасы һәм аны кую датасы)

Искәрмә. Әгәр белешмәләр имза кәгазендә күрсәтелә торган кандидатның алынмаган яисә юкка чыгарылмаган хөкем ителүе булганда, кандидатның атасының исеменнән соң имзалар кәгазендә кандидатның хөкем ителүе турындагы белешмәләр күрсәтелә. Әгәр имза кәгазендә белешмәләре булган кандидат күрсәтелергә ризалыгы турындагы гаризасында Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 39 статьясындагы 2 өлеше һәм 41 статьясындагы 2 өлеше нигезендә сәяси партиядән йә бүтән иҗтимагый берләшмәдән булуы һәм аның шушы сәяси партиядәге йә иҗтимагый берләшмәдәге статусын күрсәткән булса, бу хактагы белешмәләр имза кәгазендә кандидатның яшәү урыны турындагы белешмәләрдән соң яисә кандидатның хөкем ителүе турындагы белешмәләрдән соң күрсәтелә.

---

<1> Юллар асларындагы текст, шулай ук искәрмә һәм сноска әзерләнгән имза кәгазендә басылмаска да мөмкин.

2 нче кушымта

**Тавыш бирү йомгаклары турында беркетмәләргә кертелгән күрсәткечләрнең контроль нисбәте (саннар белән беркетмәләрнең әлеге Кодексның 78 статьясы нигезендә номер сугылган юллары билгеләнде)**

| | |
|---|---|
| 1 күбрәк яисә тигез | 3+4 |
| 2 тигез | 3+4+5 |
| 6+7 тигез | 8+9 |
| 9 тигез | 16+ беркетмәнең калган барлык юллары"; |

22) 3 – 9 нчы кушымталарны үз көчләрен югалткан дип танырга.

## 2 статья

"Татарстан Республикасы референдумы турында" 2003 елның 9 августындагы 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 8; 2005, № 3 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, № 10 (II өлеш); Ватаным Татарстан, 2011, 5 август) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 13 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"13 статья. **Референдум үткәрү инициативасын хуплап имзалар җыю**

1. Референдумда катнашучыларның имзалары имза кәгазьләре әзерләгән өчен түләү көненнән җыелырга мөмкин. Имза кәгазьләре референдумның тиешле фонды акчалары исәбеннән әзерләнергә тиеш. Референдумда катнашучыларның имзаларын җыю чоры 30 көн тәшкил итә.

2. Референдум үткәрү инициативасын хуплап җыелырга тиешле имзалар саны Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән референдумда катнашучылар санының 2 процентын тәшкил итә.

3. Имзалар референдумда катнашучылар арасында гына җыелырга мөмкин. Дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, барлык милек рәвешләрендәге оешмаларның, учреждениеләрнең идарә органнарының, референдум комиссияләренең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзаларының имзалар җыюда катнашулары, шулай ук имзалар җыю процессында референдумда катнашучыларны мәҗбүр итү һәм имзалары өчен аларны бүләкләү рөхсәт ителми. Эш урыннарында, уку урынында, хезмәт хакы, пенсияләр, пособиеләр, стипендияләр, башка социаль түләүләр бирү вакытында һәм урыннарында, шулай ук хәйрия ярдәме күрсәткән вакытта имзалар җыю тыела.

4. Имзалар җыю вакытына 18 яше тулган һәм суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез дип танылмаган граждан референдумда катнашучыларның имзаларын җыю хокукына ия. Инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиле референдумда катнашучыларның имзаларын җыючы зат белән имзалар җыю турында шартнамә төзергә мөмкин. Әлеге эш өчен түләү инициатив төркем төзегән референдум фонды аша гына гамәлгә ашырыла.

5. Референдумда катнашучыларның имзаларын җыю өчен имза кәгазьләре "Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль законның 9 нчы кушымтасы нигезендә әзерләнә һәм рәсмиләштерелә.

6. Референдум үткәрү инициативасы белән чыкканда, имза кәгазендә имза кәгазьләрен әзерләгән өчен түләү башкарылган референдум фондының махсус счеты номеры күрсәтелә.

7. Референдумда катнашучы имза кәгазенә имзасын куя һәм аны кую датасын күрсәтә, шулай ук фамилиясен, исемен, атасының исемен, туган елын (тавыш бирү көненә 18 яшендә булса, өстәмә рәвештә туган көнен һәм аен), яшәү урыны

адресын, паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы документының сериясен һәм номерын күрсәтә. Имза кәгазенә үз имзасын куя торган һәм аны кую датасын күрсәтә торган референдумда катнашучы турында күрсәткечләр референдум үткәрү инициативасын хуплап имзалар җыючы зат тарафыннан референдумда катнашучы үтенече буенча имза кәгазенә кертелергә мөмкин. Әлеге күрсәткечләр бары тик кулдан гына языла, бу чакта карандашлар куллану рөхсәт ителми. Имзасын һәм аны кую датасын референдумда катнашучы шәхсән үз кулы белән яза. Референдумда катнашучы референдум үткәрү буенча бер үк инициативаны хуплап бер генә тапкыр имза куярга хокуклы.

8. Имза кәгазенең һәркайсы референдумда катнашучыларның имзаларын җыйган зат имзасы белән таныкланырга тиеш. Имза кәгазен таныклаганда, референдумда катнашучыларның имзаларын җыйган зат үз кулы белән фамилиясен, исемен һәм атасының исемен, туу датасын, яшәү урыны адресын, паспортының яисә аны алмаштыручы документының сериясен, номерын һәм бирү датасын, аны биргән органның исемен яисә кодын күрсәтә, шулай ук имзасын куя һәм аны кую датасын күрсәтә.

9. Имза кәгазенең һәркайсы инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиле тарафыннан таныкланырга тиеш. Имза кәгазен таныклаганда, инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиле үз фамилиясе, исеме һәм атасының исеме каршына үз кулы белән имзасын куя һәм аны кую датасын күрсәтә.

10. Референдум үткәрү инициативасы белән чыгуны хуплап имзалар җыйганда, имза кәгазенең алгы һәм арткы якларын тутыру рөхсәт ителә. Ул очракта арткы як имзаларның бердәм нумерациясе белән алгы якның дәвамы булып тора, ә таныклау язмалары имза кәгазенең арткы ягында бары тик референдумда катнашучының соңгы имзасыннан соң гына кертелә.

11. Имзалар җыюны тәгәлләгәннән соң, инициатив төркемнең вәкаләтле вәкилләре референдумда катнашучыларның җыелган имзаларының гомуми санын исәплиләр һәм Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән форма буенча имзаларны җыю йомгаклары турында ике нөсхәдә беркетмә төзиләр. Беркетмәнең һәр нөсхәсенә инициатив төркемнең тиешле вәкаләтле вәкиле имза куя.";

2) $13^1$ статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1. Брошюраланган һәм номерлар сугылган имза кәгазьләре, ике нөсхәдә кәгазь чыганакта һәм машинада укыла торган рәвештә имзаларны җыю йомгаклары турында беркетмә, шулай ук имза кәгазьләрен әзерләгән өчен түләү датасын раслый торган документ инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиле (вәкаләтле вәкилләре) тарафыннан Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә референдум үткәрү инициативасын хуплап имзалар җыю срогы тәмамлана торган көндә 18 сәгатьтән дә соңга калмыйча тапшырыла.";

3) $13^2$ статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"$13^2$ статья. **Имзалар җыю, имза кәгазьләрен рәсмиләштерү тәртибен үтәүне, референдумда катнашучылар турындагы белешмәләрнең һәм референдумда катнашучылар имзаларының дөреслеген тикшерү**

1. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе имза кәгазьләрен һәм әлеге Законның 13 һәм $13^1$ статьяларында күрсәтелгән документларны кабул итеп алган көннән 14 көн эчендә референдум үткәрү инициативасын хуплап имзалар җыю, имза кәгазьләрен рәсмиләштерү тәртибен үтәүне, имза кәгазьләрендәге референдумда катнашучылар турындагы белешмәләрнең һәм аларның имзаларының дөреслеген, шулай ук инициатив төркемнең үз эшчәнлеген финанслау тәртибен һәм референдум сораулары буенча агитация үткәрү кагыйдәләрен үтәвен тикшерә.

2. Референдум үткәрү инициативасын хуплап имзалар җыю, имза кәгазьләрен рәсмиләштерү тәртибен үтәүне, имза кәгазьләрендәге референдумда катнашучылар турындагы белешмәләрнең һәм аларның имзаларының дөреслеген тикшерү өчен Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе үз карары белән Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әгъзалары, аның аппараты хезмәткәрләре, җәлеп ителгән белгечләр арасыннан эш төркемнәре төзергә мөмкин. Тикшерүгә референдумның түбәнгерәк комиссияләре әгъзалары, эчке эшләр органнары, юстиция учреждениеләре, хәрби комиссариатлар, Россия Федерациясе гражданнарын Россия Федерациясе чикләрендә булу урыны буенча һәм яшәү урыны буенча теркәү белән шөгыльләнүче органнары, шулай ук башка дәүләт органнары белгечләре арасыннан экспертлар җәлеп ителергә мөмкин. Экспертларның бәяләмәләре имза кәгазьләрендә референдумда катнашучылар турында белешмәләрне һәм аларның имзаларын дөрес түгел һәм (яисә) гамәлгә яраксыз дип тану өчен нигез булып торырга мөмкин. Экспертларның бәяләмәләре имза кәгазьләрен тикшерү ведомостьларында яисә башка документта язма рәвештә бәян ителә.

3. Референдум үткәрү инициативасы белән чыкканда, референдумда катнашучылар турында имза кәгазьләрендәге белешмәләрнең дөреслеген билгеләү өчен "Сайлаулар" ДАС кулланыла, моңа референдумда катнашучылар регистры да керә.

4. Референдум билгеләү өчен әлеге Законның 13 статьясындагы 2 пунктында билгеләнгән референдумда катнашучыларның имзалары санынннан очраклы сайлап алу (шобага салу) юлы белән тикшерү өчен сайлап алынган имза кәгазьләрендәге имзаларның кимендә 20 проценты тикшерелергә тиеш. Очраклы сайлап алу (шобага салу) процедурасы Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә. Очраклы сайлап алу, имза кәгазьләрен кабул итеп алуны раслый торган документ инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиленә тапшырылганнан соң, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясендә башкарыла. Референдумда катнашучыларның барлык имзалары һәм тикшерү өчен сайлап алынган имза кәгазьләрендәге референдумда катнашучылар турындагы аларга туры килә торган белешмәләр дә тикшерелергә тиеш.

5. Референдумда катнашучыларның имзаларын һәм имза кәгазьләрендәге референдумда катнашучылар турындагы аларга туры килә торган белешмәләрне тикшерү нәтиҗәләре буенча референдумда катнашучы имзасы дөрес йә дөрес түгел һәм (яисә) гамәлгә яраксыз дип танылырга мөмкин.

6. Бер зат өчен башка зат куйган имза дөрес түгел дип санала. Бу рәвешле куелган имза, әлеге статьяның 2 пункты нигезендә имзаларның дөреслеген тикшерү эшенә җәлеп ителгән экспертның язма бәяләмәсенә таянып, дөрес түгел дип таныла.

7. Гамәлгә яраксыз имзалар дип түбәндәгеләр таныла:

а) имза кәгазьләрен әзерләгән өчен түләү көненә кадәр җыелган референдумда катнашучылар имзалары;

б) референдумда катнашу хокукына ия булмаган затлар имзалары;

в) имза кәгазендә дөреслеккә туры килмәгән белешмәләр күрсәткән референдумда катнашучылар имзалары. Бу очракта имза Россия Федерациясе гражданнарын Россия Федерациясе чикләрендә булу урыны буенча һәм яшәү урыны буенча теркәү белән шөгыльләнүче органның рәсми белешмәсе йә әлеге статьяның 2 пункты нигезендә референдумда катнашучылар имзаларын тикшерү эшенә җәлеп ителгән эксперт бәяләмәсе булганда гына гамәлгә яраксыз дип танылырга мөмкин;

г) Федераль закон нигезендә таләп ителә торган белешмәләрнең кайсы да булса күрсәтелмәгән һәм (яисә) референдумда катнашучының үз имзасын имза кәгазенә үз кулы белән кую датасы күрсәтелмәгән референдумда катнашучылар имзалары;

д) үзләре турындагы белешмәләр имза кәгазенә кулдан язылмыйча яисә карандаш белән кертелгән референдумда катнашучылар имзалары;

е) имза кәгазенә имзаларын кую даталарында төзәтүләр булган референдумда катнашучылар имзалары, әгәр бу төзәтүләр референдумда катнашучылар тарафыннан махсус килештерелмәгән булса, шулай ук референдумда катнашучыларның имзаларны кую даталары үз куллары белән язылмаган имзалары – әлеге статьяның 2 пункты нигезендә референдумда катнашучыларның имзаларын тикшерү эшенә җәлеп ителгән эксперт бәяләмәсе нигезендә;

ж) референдумда катнашучылар турындагы аларга туры килә торган белешмәләрдә төзәтүләр булган референдумда катнашучылар имзалары, әгәр бу төзәтүләр референдумда катнашучылар яисә референдумда катнашучылар имзаларын җыючы затлар тарафыннан махсус килештерелмәгән булса;

з) референдумда катнашучыларның имза кәгазендәге барлык имзалары, әгәр имза кәгазе референдумда катнашучылар имзаларын җыйган затның һәм (яисә) инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиленең үз куллары белән куелган имзалары белән таныкланмаган булса, йә бу имзаларның берәрсе генә дөрес булмаса, йә имза кәгазе имзалар җыю мизгеленә 18 яшькә җитмәгән, референдумда катнашучылар имзаларын җыйган зат тарафыннан таныкланган булса һәм (яисә) әлеге зат суд тарафыннан хокукка сәләтсез дип танылган булса, йә имза кәгазен таныклау даталарының берәрсе генә кулдан күрсәтелмәгән яисә кертелмәгән булса, йә референдумда катнашучылар имзаларын җыйган зат турындагы белешмәләрдә һәм (яисә) шушы зат һәм (яисә) инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиле тарафыннан

имзалар кую датасында референдумда катнашучылар имзаларын җыйган зат, инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиле белән махсус килештерелмәгән төзәтүләр булса, йә референдумда катнашучылар имзаларын җыйган зат турындагы һәм (яисә) инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиле турындагы белешмәләр имза кәгазендә тулы күләмдә күрсәтелмәгән булса яисә дөреслеккә туры килмәсә, йә референдумда катнашучылар имзаларын җыйган зат турындагы белешмәләр аның үз кулы белән кертелмәгән булса;

и) "Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль законның 9 нчы кушымтасы таләпләренә туры килми торган рәвештәге, һәм (яисә) әлеге Законның 13 статьясындагы 6 пунктында каралган белешмәләр кертелмәгән, һәм (яисә) әлеге Законның 13 статьясындагы 1 пунктында каралган таләпләрне үтәмичә әзерләнгән имза кәгазендәге барлык референдумда катнашучылар имзалары;

к) әлеге Законның 13 статьясындагы 3 пунктында каралган таләпләрне бозып җыелган референдумда катнашучылар имзалары;

л) референдумда катнашучылар имзалары, әгәр имза кәгазенә референдумда катнашучылар турындагы белешмәләр имзалар куйган референдумда катнашучыларның үзләре тарафыннан һәм шул имза кәгазенә кертелгән имзаларны җыйган зат тарафыннан кертелмәгән булса, – референдумда катнашучылар имзаларын тикшерү эшенә әлеге статьяның 2 пункты нигезендә җәлеп ителгән эксперт бәяләмәсе нигезендә;

м) референдумда катнашучыларның имзаларын җыйган зат һәм (яисә) инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиле тарафыннан имза кәгазе таныклanganнан соңрак имза кәгазенә кертелгән референдумда катнашучылар имзалары;

н) имза кәгазендәге барлык референдумда катнашучылар имзалары, әгәр референдумда катнашучылар имзаларын җыйган затның таныклау язмасы инициатив төркем вәкаләтле вәкиленең таныклау язмасы кертелгәннән соңрак куелган булса.

8. Имза кәгазендә әлеге Закон таләпләренә туры килми торган тутырылган юл (тутырылган юллар) табылганда, шушы юлдагы (юллардагы) имза гына исәпкә алынмый, моңа әлеге статьяның 7 пунктындагы "з", "и" һәм "н" пунктчаларында каралган очраклар керми.

9. Әгәр әлеге статьяның 7 пунктындагы "з", "и" һәм "н" пунктчалары нигезендә референдумда катнашучы имзасының дөрес түгеллеге яисә гамәлгә яраксызлыгы билгеләнмәгән булса, имза кәгазен төзегәндә референдумда катнашучы яисә имза кәгазен таныклаучы зат белән махсус килештерелгән төзәтүләр һәм ялгышлар референдумда катнашучы имзасын гамәлгә яраксыз дип тану өчен нигез була алмый.

10. Әгәр референдумда катнашучылар имзаларын тикшергәндә бер үк затның референдум үткәрү инициативасы белән чыгуны хуплаган берничә имзасы барлыгы ачыкланса, бер генә имза дөрес дип санала, ә калган имзалар гамәлгә яраксыз дип саналалар.

11. Референдумда катнашучыларның имза кәгазьләренә кертелгән, әмма референдум үткәрү инициаторлары тарафыннан төшереп калдырылган (сызылган) имзалары, әгәр бу алар тарафыннан имза кәгазендә яисә имзалар җыю йомгаклары

турындагы беркетмәдә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә имза кәгазьләрен тапшырганчы махсус билгеләнгән булса, тикшерелмәскә һәм исәпкә алынмаска тиеш.

12. Имза кәгазьләрендәге референдумда катнашучы турындагы белешмәләрдә сүзләрне һәм даталарны шушы белешмәләрне дөрес аңлау өчен каршылык тудырмаслык итеп кыскартулар референдумда катнашучының имзасын гамәлгә яраксыз дип тану өчен нигез була алмый. Референдумда катнашучы имзасының дөреслеген сорашып белешү ысулы белән билгеләү тыела.

13. Референдумда катнашучылар имзаларын тикшергәндә, шул исәптән тикшерү өчен имзаларны сайлап алганда, референдумда катнашучыларның референдум билгеләү өчен кирәкле сандагы имзаларын тапшырган инициатив төркемнең вәкаләтле вәкилләре булырга хокуклы. Тиешле тикшерү һәм аны үткәрү вакыты турында Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе инициатив төркемнең вәкаләтле вәкилләренә хәбәр итәргә тиеш.

14. Имза кәгазьләрен тикшерү тәмамланганнан соң, йомгаклау беркетмәсе төзелә, анда референдумда катнашучыларның игълан ителгән имзалары саны, тапшырылган имзалары саны һәм тикшерелгән имзалары саны, шулай ук дөрес түгел һәм (яисә) гамәлгә яраксыз дип танылган имзалары саны күрсәтелә, аларны шундыйлар дип тануның нигезләре (сәбәпләре) күрсәтелә. Беркетмәнең күчермәсе, референдум үткәрү турындагы мәсьәлә каралырга тиешле Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе утырышына кадәр ике тәүлектән дә соңга калмыйча, инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиленә тапшырыла. Әгәр Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан имзалар кәгазьләрен тикшерү әлеге статьяның 4 пунктындагы "в" пунктчасында каралган нәтиҗәләргә китерсә, инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиле Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясеннән, йомгаклау беркетмәсе күчермәсе белән бергә, референдумда катнашучыларның имзаларын дөрес түгел һәм (яисә) гамәлгә яраксыз дип тану нигезләре (сәбәпләре) күрсәтелгән имза кәгазьләрен тикшерү ведомостьларының таныкланган күчермәләрен алырга хокуклы, аларда һәр шундый имзалар булган папканың, имза кәгазенең номерлары һәм имза кәгазендәге юл күрсәтелә, шулай ук тиешле имзаларны дөрес түгел һәм (яисә) гамәлгә яраксыз дип тану өчен нигез булып торучы рәсми документларның күчермәләрен алырга хокуклы. Йомгаклау беркетмәсе референдум үткәрү инициативасы белән чыгу нәтиҗәләре турында Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карарына кушып куела.";

4) 31 статьяның 7 пунктында "гомуми кулланылыштагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (Интернетны кертеп)" сүзләрен "файдаланылуы аерым затлар даирәсе белән генә чикләнмәгән мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә ("Интернет" челтәрен дә кертеп)" сүзләренә алмаштырырга;

5) 32 статьяның 3 пунктында "гомуми файдаланыштагы мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру (Интернетны да кертеп)" сүзләрен "файдаланылуы аерым затлар даирәсе белән генә чикләнмәгән мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә ("Интернет" челтәрен дә кертеп) урнаштыру" сүзләренә алмаштырырга;

б) 39 статьяның $4^{1}$ пунктында "гомуми файдалану" сүзләрен төшереп калдырырга;

7) 51 статьяда:

а) 5 пунктта "тавыш бирү вакыты тәмамланырга дүрт сәгатьтән дә соңга калмыйча" сүзләрен "участок комиссиясе төзелгәннән соң теләсә кайсы вакытта, ләкин тавыш бирү вакыты тәмамланырга алты сәгатьтән дә соңга калмыйча" сүзләренә алмаштырырга, түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: "Күрсәтелгән сроктан соңрак кергән гариза (телдән мөрәҗәгать) канәгатьләндерелергә тиеш түгел, бу хакта референдумда катнашучыга йә мөрәҗәгатьне тапшыруда ярдәм иткән затка гариза (телдән мөрәҗәгать) кабул ителгән вакытта турыдан-туры телдән җиткерелә.";

б) 6 пунктка "игълан итәргә" сүзләреннән соң ", шулай ук киңәш итү тавышы хокукына ия участок комиссиясе әгъзаларына һәм күзәтүчеләргә аны үткәргәндә катнашуны тәкъдим итәргә" сүзләрен өстәргә;

в) 8 пунктта "участок комиссиясе" сүзләрен "турыдан-туры югарырак комиссия" сүзләренә алмаштырырга, түбәндәге эчтәлекле җөмләләр өстәргә: "Төрле дәрәҗәдәге сайлауларда һәм (яисә) референдумнарда тавыш бирү көне туры килгән очракта, карар югарырак дәрәҗәдәге сайлауларны (референдумны) әзерләүдә һәм уздыруда катнашучы комиссия тарафыннан кабул ителә. Бу чакта тавыш бирү көнендә бер референдум участогында тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирү өчен кулланыла торган күчерелмә әрҗәләрнең максималь саны референдум участогы территориясендә теркәлгән референдумда катнашучылар санына бәйле рәвештә түбәндәгечә төзелә:

а) референдумда катнашучылар саны 501гә кадәр – тавыш бирү өчен 1 күчерелмә әрҗә;

б) референдумда катнашучылар саны 501дән алып 1001гә кадәр – тавыш бирү өчен 2 күчерелмә әрҗә;

в) референдумда катнашучылар саны 1000нән артыграк – тавыш бирү өчен 3 күчерелмә әрҗә.";

г) түбәндәге эчтәлекле $8^{1}$ пункт өстәргә:

"$8^{1}$. Әлеге статьяның 8 пунктында күрсәтелгән тиешле комиссия карары белән тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирү өчен кулланыла торган күчерелмә әрҗәләрнең әлеге статьяның 8 пунктындагы "а" һәм "б" пунктчаларында күрсәтелгән саны, түбәндәге шартларның берсе генә булса да, арттырылырга да мөмкин, әмма 1 күчерелмә әрҗәдән арттырылмаска тиеш:

а) референдум участогына берничә торак пункт территориясе керсә, һәм тавыш бирү урыны урнашкан торак пункт тавыш бирү вакыты эчендә башка торак пунктларга җәяү барып җитәрлек булмаса;

б) референдум участогы территориясендә сайлау участогы төзелмәгән сайлаучылар вакытлыча булу урыны урнашкан булса;

в) референдум участогы территориясендә "Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль законның 16 статьясындагы 10 пункты нигезендә 80 яшьтән

олырак һәм (яисә) инвалид 50дән артык сайлаучы теркәлгән булса, алар турындагы белешмәләр "Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль законның 20 статьясындагы $16^1$ пункты нигезендә тапшырылган булса.";

д) 9 пунктка түбәндәге эчтәлекле яңа икенче җөмлә өстәргә: "Алына торган бюллетеньнәрнең гомуми саны китү мизгеленә алынган гаризалар (телдән мөрәҗәгатьләр) санының 5 процентыннан артыграк булмаска тиеш (әмма кимендә ике бюллетень).";

8) 53 статьяның 34 пунктында "Интернет гомуми файдалану мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә" сүзләрен "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә" сүзләренә алмаштырырга;

9) 55 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле алтынчы абзац өстәргә:

"Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе төзи торган референдум нәтиҗәләре турындагы җыелма таблицага шулай ук тиешле территория комиссиясе тарафыннан алынган бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары саны, участок комиссияләренә бирелгән бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары саны, тиешле территория комиссиясе тарафыннан юкка чыгарылып, файдаланылмаган бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары саны һәм тиешле территория комиссиясе тарафыннан югалтылган бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары саны күрсәтелә.";

10) 56 статьяның 4 пунктында "Интернет гомуми файдалану мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә" сүзләрен "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә" сүзләренә алмаштырырга;

11) 58 статьяның 4 пунктында "Интернет гомуми файдалану мәгълүмат-телекоммуникация челтәре" сүзләрен "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәре" сүзләренә алмаштырырга;

12) 1 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга.

**3 статья**

"Җирле референдум турында" 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (II өлеш); 2005, № 3 (I өлеш); 2008, № 5 (II өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); Ватаным Татарстан, 2011, 3 август) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 14 статьяда:

а) 5 – 8 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5. Имзалар җыю мизгеленә 18 яше тулган һәм суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез дип танылмаган граждан референдумда катнашучыларның имзаларын җыю хокукына ия. Инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиле

референдумда катнашучыларның имзаларын җыючы зат белән имзалар җыю турында шартнамә төзергә мөмкин. Әлеге эш өчен түләү инициатив төркем төзегән референдум фонды акчаларыннан гамәлгә ашырыла.

6. Референдумда катнашучыларның имзаларын җыю өчен имза кәгазьләре "Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль законның 9 нчы кушымтасы нигезендә әзерләнә һәм рәсмиләштерелә.

7. Референдумда катнашучы имза кәгазендә үз имзасын куя һәм аны кую датасын күрсәтә, шулай ук үзенең фамилиясен, исемен, атасының исемен, туган елын (тавыш бирү көненә 18 яшендә булса, өстәмә рәвештә туган көнен һәм аен), яшәү урыны адресын, паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы документының сериясен, номерын күрсәтә. Имза кәгазендә үзенең имзасын куя торган һәм аны кую датасын күрсәтә торган референдумда катнашучы турында күрсәткечләр референдум үткәрү инициативасын хуплап имзалар җыючы зат тарафыннан референдумда катнашучы үтенече буенча имза кәгазенә кертелергә мөмкин. Әлеге күрсәткечләр бары тик кулдан гына языла, бу чакта карандашлар куллану рөхсәт ителми. Имзасын һәм аны кую датасын референдумда катнашучы шәхсән үз кулы белән яза. Референдумда катнашучы референдум үткәрү буенча бер үк инициативаны хуплап бер генә мәртәбә имза куярга хокуклы.

8. Имза кәгазенең һәркайсы референдумда катнашучыларның имзаларын җыйган зат имзасы белән таныкланырга тиеш. Имза кәгазен таныклаганда, референдумда катнашучыларның имзаларын җыйган зат үз кулы белән фамилиясен, исемен һәм атасының исемен, туу датасын, яшәү урыны адресын, паспортының яисә аны алмаштыручы документының сериясен, номерын һәм бирү датасын, аны биргән органның исемен яисә кодын күрсәтә, шулай ук имзасын куя һәм аны кую датасын күрсәтә.";

б) түбәндәге эчтәлекле $8^1$ – $8^2$ пунктлар өстәргә:

"$8^1$. Имза кәгазенең һәркайсы инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиле тарафыннан таныкланырга тиеш. Имза кәгазен таныклаганда, инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиле үз фамилиясе, исеме һәм атасының исеме каршына үз кулы белән имза куя һәм аны кую датасын күрсәтә.

$8^2$. Референдум үткәрү инициативасы белән чыгуны хуплап имзалар җыйганда, имза кәгазенең алгы һәм арткы якларын тутыру рөхсәт ителә. Ул чакта арткы як имзаларның бердәм нумерациясе белән алгы якның дәвамы булып тора, ә таныклау язмалары имза кәгазенең арткы ягында бары тик референдумда катнашучының соңгы имзасыннан соң гына куела.";

в) 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"9. Имзалар җыюны тәгәлләгәннән соң, инициатив төркемнең вәкаләтле вәкилләре референдумда катнашучыларның җыелган имзаларының гомуми санын исәплиләр һәм муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән форма буенча имзаларны җыю йомгаклары турында ике нөсхәдә беркетмә төзиләр. Беркетмәнең һәр нөсхәсенә инициатив төркемнең тиешле вәкаләтле вәкиле имза куя.";

2) 15 статьяда:

а) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1. Брошюраланган һәм номерлар сугылган имза кәгазьләре, ике нөсхәдә кәгазь чыганакта һәм машинада укыла торган рәвештә имзаларны җыю йомгаклары турында беркетмә, шулай ук имза кәгазьләрен әзерләгән өчен түләү датасын раслый торган документ инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиле (вәкаләтле вәкилләре) тарафыннан муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенә референдум үткәрү инициативасын хуплап имзалар җыю срогы тәмамлана торган көндә 18 сәгатьтән дә соңга калмыйча тапшырыла.";

б) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3. Муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе референдум үткәрү инициативасын хуплап җыелган имзаларны җыю, имза кәгазьләрен рәсмиләштерү тәртибен үтәүне, референдумда катнашучылар турындагы белешмәләрнең һәм референдумда катнашучылар имзаларының дөреслеген тикшерә. Муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе карары буенча әлеге тикшерүне үткәрү өчен түбәнгерәк референдум комиссияләре әгъзалары, эчке эшләр органнары, юстиция учреждениеләре, хәрби комиссариатлар, Россия Федерациясе гражданнарын Россия Федерациясе чикләрендә булу урыны буенча һәм яшәү урыны буенча теркәү белән шөгыльләнүче органнары, шулай ук башка дәүләт органнары белгечләре арасыннан экспертлар җәлеп ителергә мөмкин. Экспертларның бәяләмәләре имза кәгазьләрендә референдумда катнашучылар турында белешмәләрне һәм аларның имзаларын дөрес түгел һәм (яисә) гамәлгә яраксыз дип тану өчен нигез булып торырга мөмкин. Экспертларның бәяләмәләре имзалар кәгазьләрен тикшерү ведомостьларында яисә башка документта язма рәвештә бәян ителә. Территориаль бүленеше булмаган шәһәр округы, муниципаль район референдумын үткәрү инициативасы белән чыкканда, референдумда катнашучылар турында имза кәгазьләрендәге белешмәләрнең дөреслеген билгеләү өчен "Сайлаулар" ДАС кулланыла, моңа референдумда катнашучылар регистры да керә. Территориаль бүленеше булган шәһәр округы, җирлек референдумын үткәрү инициативасы белән чыкканда, имза кәгазьләрендә референдумда катнашучылар турындагы белешмәләрнең дөреслеген билгеләү өчен Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары белән "Сайлаулар" ДАС кулланыла, моңа референдумда катнашучылар регистры да керә.";

в) 6 – 11 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"6. Референдумда катнашучыларның имзаларын һәм имза кәгазьләрендәге референдумда катнашучылар турында аларга туры килә торган белешмәләрне тикшерү нәтиҗәләре буенча референдумда катнашучы имзасы дөрес йә дөрес түгел һәм (яисә) гамәлгә яраксыз дип танылырга мөмкин.

7. Бер зат исеменнән икенче зат куйган имза дөрес түгел дип санала. Шушы рәвешле куелган имза, әлеге статьяның 3 пункты нигезендә имзаларның дөреслеген тикшерү эшенә җәлеп ителгән экспертның язма бәяләмәсенә таянып, дөрес түгел дип таныла.

8. Гамәлгә яраксыз имзалар дип түбәндәгеләр таныла:

а) имза кәгазьләрен әзерләү өчен түләү көненә кадәр җыелган референдумда катнашучылар имзалары;

б) референдумда катнашу хокукына ия булмаган затлар имзалары;

в) имза кәгазендә дөреслеккә туры килмәгән белешмәләр күрсәткән референдумда катнашучылар имзалары. Бу очракта имза Россия Федерациясе гражданнарын Россия Федерациясе чикләрендә булу урыны буенча һәм яшәү урыны буенча теркәү белән шөгыльләнүче органның рәсми белешмәсе йә әлеге статьяның 3 пункты нигезендә референдумда катнашучылар имзаларын тикшерү эшенә җәлеп ителгән эксперт бәяләмәсе булганда гына гамәлгә яраксыз дип танылырга мөмкин;

г) "Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль закон нигезендә таләп ителә торган белешмәләрнең кайсы да булса күрсәтелмәгән һәм (яисә) референдумда катнашучының үз имзасын имза кәгазенә үз кулы белән кую датасы күрсәтелмәгән референдумда катнашучылар имзалары;

д) үзләре турындагы белешмәләр имза кәгазенә кулдан язылмыйча яисә карандаш белән кертелгән референдумда катнашучылар имзалары;

е) имза кәгазенә имзаларын кую даталарында төзәтүләр булган референдумда катнашучылар имзалары, әгәр бу төзәтүләр референдумда катнашучылар тарафыннан махсус килештерелмәгән булса, шулай ук референдумда катнашучыларның имзаларны кую даталары үз куллары белән язылмаган имзалары – әлеге статьяның 3 пункты нигезендә референдумда катнашучыларның имзаларын тикшерү эшенә җәлеп ителгән эксперт бәяләмәсе нигезендә;

ж) референдумда катнашучылар турындагы аларга туры килә торган белешмәләрдә төзәтүләр булган референдумда катнашучылар имзалары, әгәр бу төзәтүләр референдумда катнашучылар яисә референдумда катнашучылар имзаларын җыючы затлар тарафыннан махсус килештерелмәгән булса;

з) референдумда катнашучыларның имза кәгазендәге барлык имзалары, әгәр имза кәгазе референдумда катнашучылар имзаларын җыйган затның һәм (яисә) инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиленең үз куллары белән куелган имзалары белән таныкланмаган булса, йә бу имзаларның берәрсе генә дөрес булмаса, йә имза кәгазе имзалар җыю мизгеленә 18 яшькә җитмәгән, референдумда катнашучылар имзаларын җыйган зат тарафыннан таныкланган булса һәм (яисә) әлеге зат суд тарафыннан хокукка сәләтсез дип танылган булса, йә имза кәгазен таныклау даталарының берәрсе генә кулдан күрсәтелмәгән яисә кертелмәгән булса, йә референдумда катнашучылар имзаларын җыйган зат турындагы белешмәләрдә һәм (яисә) шушы зат һәм (яисә) инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиле тарафыннан имзалар кую датасында референдумда катнашучылар имзаларын җыйган зат, инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиле белән махсус килештерелмәгән төзәтүләр булса, йә референдумда катнашучылар имзаларын җыйган зат турындагы һәм (яисә) инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиле турындагы белешмәләр имза кәгазендә тулы күләмдә күрсәтелмәгән булса яисә дөреслеккә туры килмәсә, йә референдумда катнашучылар имзаларын җыйган зат турындагы белешмәләр аның үз кулы белән кертелмәгән булса;

и) "Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль законның 9 нчы кушымтасы таләпләренә туры килми торган рәвештәге һәм (яисә) әлеге

Законның 14 статьясындагы 2 пунктында каралган таләпләрне үтәмичә әзерләнгән имза кәгазендәге барлык референдумда катнашучылар имзалары;

к) әлеге Законның 14 статьясындагы 4 пунктында каралган таләпләрне бозып җыелган референдумда катнашучылар имзалары;

л) референдумда катнашучылар имзалары, әгәр имза кәгазенә референдумда катнашучылар турындагы белешмәләр имзалар куйган референдумда катнашучыларның үзләре тарафыннан һәм шул имза кәгазенә кертелгән имзаларны җыйган зат тарафыннан кертелмәгән булса, – референдумда катнашучылар имзаларын тикшерү эшенә әлеге статьяның 3 пункты нигезендә җәлеп ителгән эксперт бәяләмәсе нигезендә;

м) референдумда катнашучыларның имзаларын җыйган зат һәм (яисә) инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиле тарафыннан имза кәгазе таныкланганнан соңрак имза кәгазенә кертелгән референдумда катнашучылар имзалары;

н) имза кәгазендәге барлык референдумда катнашучылар имзалары, әгәр референдумда катнашучылар имзаларын җыйган затның таныклау язмасы инициатив төркем вәкаләтле вәкиленең таныклау язмасы кертелгәннән соңрак куелган булса.

9. Имза кәгазендә әлеге Закон таләпләренә туры килми торган тутырылган юл (тутырылган юллар) табылганда, шушы юлдагы (шул юллардагы) имза гына исәпкә алынмый, моңа әлеге статьяның 8 пунктындагы "з", "и" һәм "н" пунктчаларында каралган очраклар керми.

10. Әгәр референдумда катнашучылар имзаларын тикшергәндә бер үк затның референдум үткәрү инициативасы белән чыгуны хуплаган берничә имзасы барлыгы ачыкланса, бер генә имза дөрес дип санала, ә калган имзалар гамәлгә яраксыз дип саналалар.

11. Әгәр әлеге статьяның 8 пунктындагы "з", "и" һәм "н" пунктчалары нигезендә референдумда катнашучы имзасының дөрес түгеллеге яисә гамәлгә яраксызлыгы билгеләнмәгән булса, имза кәгазен төзегәндә референдумда катнашучы яисә имза кәгазен таныклаучы зат белән махсус килештерелгән төзәтүләр һәм ялгышлар референдумда катнашучы имзасын гамәлгә яраксыз дип тану өчен нигез була алмый.";

3) 33 статьяның 7 пунктында "гомуми кулланылыштагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә ("Интернет"ны да кертеп)" сүзләрен "файдаланылуы аерым затлар даирәсе белән генә чикләнмәгән мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә ("Интернет" челтәрен дә кертеп)" сүзләренә алмаштырырга;

4) 34 статьяның 3 пунктында "гомуми файдаланыштагы мәгълүмати-телекоммуникация челтәрләрендә ("Интернет"ны да кертеп)" сүзләрен "файдаланылуы аерым затлар даирәсе белән генә чикләнмәгән мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә ("Интернет" челтәрен дә кертеп)" сүзләренә алмаштырырга;

5) 41 статьяның $4^1$ пунктында "гомуми файдалану" сүзләрен төшереп калдырырга;

6) 53 статьяда:

а) 5 пунктта "тавыш бирү вакыты тәмамланырга дүрт сәгатьтән дә соңга калмыйча" сүзләрен "участок комиссиясе төзелгәннән соң теләсә кайсы вакытта, ләкин тавыш бирү вакыты тәмамланырга алты сәгатьтән дә соңга калмыйча" сүзләренә алмаштырырга, түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: "Күрсәтелгән сроктан соң кергән гариза (телдән мөрәҗәгать) канәгатьләндерелергә тиеш түгел, бу хакта референдумда катнашучыга йә мөрәҗәгатьне тапшыруда ярдәм иткән затка гариза (телдән мөрәҗәгать) кабул ителгән вакытта турыдан-туры телдән җиткерелә.";

б) 6 пунктта "игълан итәргә" сүзләреннән соң ", шулай ук участок комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзаларына һәм күзәтүчеләргә аны үткәргәндә катнашуны тәкъдим итәргә" сүзләрен өстәргә;

в) 8 пунктта "участок комиссиясе" сүзләрен "турыдан-туры югарырак комиссия карары белән, ә җирле референдум үткәргәндә референдум округы территориясе референдум участогы территориясе белән туры килсә, – участок комиссиясе" сүзләренә алмаштырырга, түбәндәге эчтәлекле җөмләләр өстәргә: "Төрле дәрәҗәдәге сайлауларда һәм (яисә) референдумнарда тавыш бирү көне туры килгән очракта, карар югарырак дәрәҗәдәге сайлауларны (референдумны) әзерләүдә һәм уздыруда катнашучы комиссия тарафыннан кабул ителә. Бу чакта тавыш бирү көнендә бер референдум участогында тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирү өчен кулланыла торган күчерелмә әрҗәләрнең максималь саны референдум участогы территориясендә теркәлгән референдумда катнашучылар санына бәйле рәвештә түбәндәгечә төзелә:

а) референдумда катнашучылар саны 501гә кадәр – тавыш бирү өчен 1 күчерелмә әрҗә;

б) референдумда катнашучылар саны 501дән алып 1001гә кадәр – тавыш бирү өчен 2 күчерелмә әрҗә;

в) референдумда катнашучылар саны 1000нән артыграк – тавыш бирү өчен 3 күчерелмә әрҗә.";

г) түбәндәге эчтәлекле $8^1$ пункт өстәргә:

"$8^1$. Әлеге статьяның 8 пунктында күрсәтелгән тиешле комиссия карары белән тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирү өчен кулланыла торган күчерелмә әрҗәләрнең әлеге статьяның 8 пунктындагы "а" һәм "б" пунктчаларында күрсәтелгән саны, түбәндәге шартларның берсе генә булса да, арттырылырга да мөмкин, әмма ул 1 күчерелмә әрҗәдән арттырылмаска тиеш:

а) референдум участогына берничә торак пункт территориясе керсә, һәм тавыш бирү урыны урнашкан торак пункт тавыш бирү вакыты эчендә башка торак пунктларга җәяү барып җитәрлек булмаса;

б) референдум участогы территориясендә референдум участогы төзелмәгән референдумда катнашучыларның вакытлыча булу урыны урнашкан булса;

в) референдум участогы территориясендә "Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль законның 16 статьясындагы 10 пункты нигезендә 80 яшьтән олырак һәм (яисә) инвалид 50дән артык сайлаучы теркәлгән булса, алар турындагы белешмәләр "Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм

референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль законның 20 статьясындагы $16^1$ пункты нигезендә тапшырылган булса.";

д) 9 пунктка түбәндәге эчтәлекле яңа икенче җөмлә өстәргә: "Алына торган бюллетеньнәрнең гомуми саны китү мизгеленә алынган гаризалар (телдән мөрәҗәгатьләр) санының 5 процентыннан артыграк булмаска тиеш (әмма кимендә ике бюллетень).";

7) 55 статьяның 31 пунктында "гомуми файдалану" сүзләрен төшереп калдырырга;

8) 61 статьяның 4 пунктында "гомуми файдаланудагы "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәре" сүзләрен "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәре" сүзләренә алмаштырырга;

9) 1 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга.

**4 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2011 елның 20 декабре
№ 106-ТРЗ